Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Яңа Аксубай авыл җирлеге Советы
КАРАР

№ 80 26 ноябрь 2018 ел

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлегендә Муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарының үтәлешен тикшереп торуны камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 30.10.2018 ел, № 382-ФЗ Федераль закон нигезендә Яңа Аксубай авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Яңа Аксубай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Яңа Аксубай авыл җирлеге Советының 22.06.2018 ел, № 69 карары белән расланган үзгәреш кертергә.

3 бүлекнең 16 бүлегендәге 1 өлешенең 2 пункты түбәндәге эчтәлекне бәян итәргә: «шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерциячел оешма белән идарә итүдә яки коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (сәяси партия белән идарә итүдән тыш; һөнәр берлеге органы белән, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланма органы белән идарә итүдә түләүсез катнашырга; муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппараты; съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашу; күрсәтелгән коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партия һәм һөнәри берлек органыннан, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органыннан тыш) тарафыннан бердәнбер башкарма орган сыйфатында түләүсез идарә итүдә яки аларның коллегиаль идарә органнары составына кергәндә яллаучы (эш бирүче) вәкиле рөхсәте белән алынган, муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән), оешманың идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез

нигездә тәкъдим итүдән тыш, гамәлгә куючы (акционер, катнашучы) муниципаль берәмлек муниципаль берәмлек исеменнән оешманы оештыручы яисә муниципаль милектә булган акцияләр белән идарә итү вәкаләтләрен башкару тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә (устав капиталында катнашу өлешләре); федераль законнарда каралган башка очракларда;

33 статья 2 пункт түбәндәге эчтәлектәге 5 пунктчага өстәргә:
«5) тиешле муниципаль органның коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсенең коррупциячел хокук бозуны кылуның факттагы шартлары күрсәтелә торган коррупциячел хокук бозуны кылу турындагы доклады һәм муниципаль хезмәткәрнең ризалыгы белән һәм аның тарафыннан коррупциячел хокук бозу фактын тану шарты белән генә язма аңлатмасы (ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендә түләтүне куллануддан тыш);».
2. Әлеге карарны Яңа Аксубай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru һәм Аксубай муниципаль районының Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы мәгълүмати сайты (http://aksubayevo.tatarstan.ru) " Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Аксубай муниципаль районы
Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгы
Советы Рәисе М. М. Сөләйманкин